| « **Каралды** » | « **Килешенде** » | « **Расланды** » |
|---|---|---|
| Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының МБ житәкчесе ____________/Г.Г.Фәтхуллова/ Беркетмә№1 «25 » нче август 2021 нче ел | Укыту эшләре буенча директор урынбасары ____________/Р.К.Таһирова/ « 25 »нче август 2021 нче ел | Мәктәп директоры ____________/Т.Н.Петрова/ Боерык №78 «28 »нче август 2021 нче ел |

Татарстан Республикасы
Казан шәһәре Совет районы “П.А.Полушкин исемендәге 101 нче
урта гомуми белем бирү мәктәбе - Мәгариф үзәге” муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе
Таһиорва Гәүһәрия Әсхәт кызы кызы,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Дәрестән тыш эшчәнлекнең эш программасы
**«Халкыбызның күңел җәүһәрләре»**

**5-9 нчы сыйныфлар өчен дәрестән тыш чаралар программасы**

8 нче Б” сыйныфы

Педагогик совет утырышында гамәлгә керде:
Беркетмә №1
« 25 »нче август 2021 нче ел

2020-2021 нче уку елы

**«Халкыбызның күңел җәүһәрләре»**

**Аңлатма язуы**

Бүгенге көндә җөмһүриятебездә яшь буынны халкыбызның рухи һәм матди хәзинәләренә таянып, педагогик мирасын кулланып, милли – төбәк компонентларыннан файдаланып тәрбияләү җитди бурычка әверелде. Мәктәпләрдә укыту – тәрбия эшен камилләштерү максаты белән халык педагогикасы хәзинәләрен файдалану кирәклеге дә көн тәртибенә килеп басты. Яшь буынны үз туган телендә сөйләшүче, халкын сөюче, аның үткәнен һәм бүгенгесен белүче, киләчәген күзаллаучы, үз милләтен кайгыртучы, иҗади сәләтле буын итеп тәрбияләү эшен халык педагогикасыннан башка күз алдына да китереп булмый. Ә бүген халкыбызның милли традицияләрен торгызу, саклау һәм киләчәк буыннарга тапшыру өчен мөмкинлекләр зур.

Әлеге программа халкыбызның милли үзенчәлекләрен, сыйфатларын, гореф – гадәтләрен, йола һәм бәйрәмнәрен торгызу, яңарту чорында яшь буында милли үзаң тәрбияләүне максат итеп куя, аны тормышка ашыру юлларын билгели. Шулай ук кешенең туган иленә, җиренә, халкына мәхәббәт тәрбияләү, туган авылының тарихын өйрәнү һәм аның истәлекләрен саклау, милли һөнәрләрен өйрәтү дә күздә тотыла. Аларны өйрәнү балаларның рухи үсешенә этәргеч була.

Һәр милләтнең, шул исәптән татарларның да, иң изге, мәңгелек педагогик хыялы – һәрьяктан камил шәхес тәрбияләү. Ана сөте белән кергән туган тел аша сабыйда газиз әнкәсенә, әткәсенә, туганнарына, туган туфрагына, чишмә - урманнарга, кош – кортларга, гомумән, тереклек дөньясына мәхәббәт, аны белергә, өйрәнергә омтылу хисләре тәрбияләнә.

Милләт белән горурлану хисе аның рухи һәм матди мәдәниятен белү белән турыдан – туры бәйләнгән. Аны белми торып, халкыңның дөнья халыклары арасында тоткан урынын билгеләп булмый, шөһрәт казанган артистларын, язучы – шагыйрьләрен, милләт зыялыларын белми торып, милләт белән горурланып булмый.

Халкыбызның авыз иҗаты әсәрләре – яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә кыйммәтле чыганак. Халкыбызның бай рухлы, кешеләрне гүзәл киләчәккә рухландыручы әкиятләре, киң колачлы җырлары, тапкыр мәкальләре, үзенчәлекле табышмаклары киләчәк буынны милләт тормышын дәвам итәрлек, аны үстерүгә өлеш кертерлек итеп тәрбияләүдә зур рухи чишмә, чыганак булып тора. Балада эстетик ләззәтләнү, шатлык, канәгатьләнү хисе уята.

Шулай ук татар халкының милли киемнәре, милли бизәкләр, кул эшләре, җырлы – биюле уеннар - тәрбия өлкәсендә тупланган бай тәҗрибә. Алар аша бала кешенең нинди булырга тиешлегенә үзенең мөнәсәбәтен белдерә, үзе омтылган, үзе теләгән үрнәкне иң гүзәл, иң күркәм, югары рухи сыйфатлар белән бизи. Укучылар җырлы – биюле уеннарны бигрәк яратып башкаралар.

Татар халык уеннары балаларның иң яраткан шөгыле.Уеннар тизлек, зирәклек, җитезлек сорый. Башлангыч класс укучысы мөстәкыйль эшләргә, уйнарга, уйларга тырыша. Уеннар барышында үзе үк үзгәреш кертә ала, дәрестән тыш вакытта төрле уеннар кертергә мөмкин. Һәрбер уенны сайлаганда баланың яшь үзенчәлеге исәпкә алына. Алар балаларга төрле яклап ачылырга ярдәм итә, акыл, аралашу үсешенә йогынты ясый. Укытучы уен сайлаганда балаларда бер – берсенә карата дустанә мөнәсәбәт урнаштыру, төгәл һәм дөрес бәя бирә белү, таләпчәнлек кебек сыйфатлар тәрбияләүне күздә тота.

Һәр милләтнең үзенә хас бәйрәмнәре була. Алар халыкның милли горурлык, милли хисләр культурасын тәрбияләргә, формалаштырырга ярдәм итеп кенә калмыйлар, шул хисләрне кичергән кешедә рухи канәгатьләнү дә тудыралар. Программада халкыбызга хас сыйфатлар тәрбияләүдә гореф – гадәт, йола, бәйрәмнәрне торгызу максатыннан күп төрле эш формалары тәкъдим ителә.

Балада милли үзаң тәрбияләүдә гаилә шәҗәрәсен өйрәнүне оештыру бик отышлы. Балага 7 буын бабасының тарихын ачыкларга кирәк. Гаилә тарихы балага көчле этәргеч булып хезмәт итә. Кешелек туплаган рухи байлык, әдәп - әхлак кагыйдәләрен үтемле итеп җиткерү өчен әби – бабаларыбызның, төрле авырлыклар белән яшәүләренә карамастан, сынмавы, сабыр, инсафлы, мәрхәмәтле булып калуын, саф татарча, ачык сөйләшүен җиткерергә кирәк. Сөйләм, киенү, өстәл янында, җәмәгать урыннарында үз – үзеңне тоту кагыйдәләрен өйрәнү бик мөһим.

Укытучы белем бирүче генә түгел, чын мәгънәсендә тәрбияче дә. Ул яшь кешенең эчке дөньясын, сәләтен, әхлакый сыйфатларын, психологик үзенчәлекләрен күздә тотып эшләргә бурычлы.

Хәзерге вакытта җәмгыятьтә зур үзгәрешләр бара. Укытучы алдында шәхеснең акыл эшчәнлеген төрле яклап үстерүне күздә тотып, никадәр яңа алымнар, шартлар, технологияләр барлыкка килде. Шулар арасында милли рухлы хәзинәбез күмелеп калмасын иде. Безнең рухи байлыгыбыз, милли традицияләребез исән, алар безгә бүген һәм киләчәк өчен кирәк.

Балаларда милли үзаң тәрбияләү чаралары, халык педагогикасы мирасы бай булса да, дәрестә аларга бик аз вакыт бирелә. Алар белән таныштыруда класстан тыш тәрбия формалары класс җитәкчесенә нык ярдәм итә.

Түгәрәкнең **юнәлеше:**

- Балаларның эстетик зәвыгын, иҗади фантазияләрен үстерү;

- Балаларда традицияләребезгә нигезләнгән үзара аралашу культурасы булдыру.

Программаны төзегәндә түбәндәге **максатларны** куйдык:

Дәүләт теле буларак татар теленең аралашу даирәсен киңәйтү, аның дәрәҗәсен күтәрү, телгә мөнәсәбәттә ихтирам тәрбияләү.

**Төп бурычлар:**

-укучыларда халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре, дине, татар халкының язучылары, шагыйрьләре, драматурглары, артистлары, гомумән, күренекле шәхесләрен өйрәнү аркылы туган телгә һәм халкыбызга мәхәббәт һәм ихтирам хисләре тәрбияләү.

- халкыбызның йолалары, традицияләре, бәйрәмнәре, җырлы – биюле уеннары аркылы бала шәхесендә олыларга карата хөрмәт, табигатькә сакчыл караш, үзара хөрмәт һәм ярдәмләшү хисләре тәрбияләү;



-балаларда аңлы рәвештә үз сәламәтлекләренә карата уңай мөнәсәбәт тудыру, ягъни сәламәт яшәү рәвеше булдыруларына ирешү;

-татар халкының әдәпле, әхлаклы, инсафлы, мәрхәмәтле булуын балалар аңына төшендерү;

-татар әдәбиятыннан өстәмә мәгълүматлар бирү;

-олимпиада,  бәйгеләргә әзерлек эше алып бару;

-укучыларны иҗат эше белән кызыксындыру, иҗади сәләтен үстерүгә шартлар тудыру;

-әдәби әсәрләр укуга тарту;

-әдәбиятны аңларга, яратырга өйрәнергә ярдәм итү, эстетик зәвык тәрбияләү;

-укучыга үзе теләгән әсәрләр белән эшләргә, эзләнергә, иҗат итәргә юл ачу;

-мәстәкыйль эзләнүгә этәргеч ясау;

-якташ язучылар иҗатын өйрәнү;

Программа эчтәлегеннән чыгып һәм ФГОС таләпләренә туры китереп, Россия гражданины шәхесен рухи - әхлакый яктан үстерү, тәрбияләү Концепциясе нигезендә атнага 1 дәрес исәбеннән, 5 нче класста - 34 дәрес, 6 нчы  класста – 34 дәрес,7 нче класста - 34 дәрес

Эстетик юнәлештәге эшчәнлектә түбәндәге **нәтиҗәләр** көтелә:

* үз ана телендә чиста, матур  сөйләшә, аралаша белү;
* сөйләм әдәбен үзләштерү;
* туган ягының мәдәниятен аңлау, танып белү;
* татар халкының зыялы кешеләре турында күзаллау тудыру;
* татар халкының гореф – гадәт, йола, бәйрәмнәрен үзләштерү, яңадан торгызу;
* сәнгатькә тартылу;

Программаның **актуальлеге**:

Мәктәпнең яңарыш чоры кичерүе, яңа федераль белем бирү стандартларына күчү сәбәпле, татар телен тирәнтен өйрәнү ихтыяҗы туа, аралашу культурасы булдыру кирәклеге ачыклана.

Укучыларның белем һәм күнекмәләренә таләпләр:

- яшьтәшләре һәм өлкәннәр  белән аралашканда сөйләм культурасы нормаларына үтәргә;

-үз фикерен дәлилле, башкаларга төгәл итеп җиткерә белергә;

- халкыбызның милли хәзинәләреннән булган халык авыз иҗаты әсәрләрен, балалар язучыларын белергә тиеш.

- матур әдәбиятның үзенчәлекләрен аңлый, тоя белү.

**Үз белемеңне күтәрү**

Фән-мәдәният яңалыклары белән танышып бару.
Танылган кешеләр белән аралашу, очрашулар оештыру.
Вакытлы матбугат белән даими танышу.
Театр, концерт, кичәләргә йөрү.
Семинар-конференцияләрдә катнашу, чыгышлар ясау.
Тәҗрибә уртаклашу.

**Ата-аналар белән эш**

Балаларның ата-аналары белән элемтәдә тору.
Ата-аналарны бәйрәм һәм кичәләргә чакыру.
Ата-аналар белән берлектә экскурсиягә баруны оештыру.



**Сәламәтлекне саклау**

Утырышларны ялыктырмаслык итеп үткәрү.

Ял минутлары уздыру.

Куркынычсызлык буенча инструктаж үткәрү.

## Программа эчтәлеге

### 1 нче бүлек. Туган ягым.

1. Мин Татарстанда яшим. Мин яшәгән район. Шәһәремнең матур җирләре. Казан шәһәренә экскурсияләр.
2. Дәрвишләр бистәсенең тарихы белән танышу (кайчан барлыкка килгән,аның төзелешләре).
3. Татар халкының бәйрәмнәре белән танышу: “Сөмбелә”, “Нәүрүз” һ.б.

### 2 нче бүлек. Халкымның күңел бизәкләре.

1. Сандык һәм аның тышкы бизәкләре.
2. “Чиккән сөлге, суккан сөлге- Әбинең истәлеге”.
3. “Ашъяулыкта бизәкләр”
4. “Кулъяулыгым – сиңа истәлегем”
5. Салфетка. Алъяпма, аның бизәкләре.
6. Бала бишеге.

### 3 нче бүлек. Татар халкының милли киемнәре.

1. Татар халкының милли киемнәре белән танышу: хатын – кызлар һәм ирләр өчен бәйрәм һәм эш, концерт киемнәре.
2. Милли күлмәк, аның үзенчәлекләре белән танышу. Күлмәк ясау һәм аны милли бизәкләр белән бизәү.
3. Алъяпкыч, андагы бизәкләр.
4. Татар хатын – кызларының милли калфагы.
6. Түбәтәй.

### 4 нче бүлек. Татар халкының җырлы – биюле уеннары.

1. “Өчле” биюе.
2. “Чума үрдәк, чума каз”.
3. “Ачык авыз”.

4. “Күрсәт әле, үскәнем”.
5. “Кәрия – Зәкәрия”.

**5 нче бүлек. Татар халык әкиятләре.**

1. “Шүрәле”, “Су анасы” әкиятләрен өйрәнеп, иллюстрацияләр ясау
2 “Гөлчәчәк”, “Үги кыз” әкиятләрен өйрәнү, иллюстрацияләр ясау
3. “Таңбатыр” әкиятен өйрәнү, рәсемен ясау.
4. Татар халык әкиятләрен өйрәнү, арадан берсен сәхнәләштерү.

**6 нчы бүлек. Татар җырчылары иҗаты.**

1. Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова иҗаты
2. Салават Фәтхетдинов иҗаты
3. Яшь җырчылар белән танышу

**7 нче бүлек. Күренекле театр артистлары.**

1. “Нәҗибә Ихсанова – халкыбызның энҗе бөртеге”.
2. “Шәүкәт Биктимеров – милләтебез өлгесе”.

**8 нче бүлек. Якташлар авазы.**

1.Мәхмүт Хөсәен.
Язучының тормышы, иҗат юлы. Җыелган мәгълүматлардан альбом ясау. Шигырьләрен укып өйрәнү.
2. Нурихан Фәттах иҗаты.
3. Атилла Расих иҗаты.
4. Әминә Бикчәнтәева иҗаты.
5. Фәүзия Бәйрәмованың тормыш юлы

**9 нчы бүлек. Нәсел шәҗәрәсе.**

1. Үзеңнең нәсел – ыруыңны өйрәнү.
2. Нәсел агачын төзү.

**Дәрестән тыш чаралар календарь – тематик планлаштыру**



**8нче сыйныфы т**

| № | Тема | Сәгать саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт |
| 1. | Туган мәктәбем. Мәктәп музеена экскурсия | 1 | 02.09.21. – 04.09.21. | |
| 2. | Туган ягыбыз табигатенә көзге экскурсия: «Ашарга яраклы һәм агулы гөмбәләр» | 1 | 06.09.21. – 11.09.21. | |
| 3. | «Әбиемнең балачагы» *(очрашу, котлау концерты).* | 1 | 13.09.21. – 18.09.21 | |
| 4. | Халкыбызның күңел җәүһәрләре: «Халык һөнәрләре». | 1 | 20.09.21. – 25.09.21. | |
| 5 | «Түбәтәй бизәү» *(гамәли эш).* | 1 | 27.09.21. – 02.10.21. | |
| 6. | «Флаг һәм герб нәрсә сөйли». Татарстан символикасы. / | 1 | 04.10.21. – 09.10.21. | |
| 7. | Саулык - *зур байлык (әңгәмәләр).* «Сәламәт тәндә - сәламәт акыл». | 1 | 11.10.21. – 16.10.21. | |
| 8. | Тапкырлар, зирәкләр бәйгесе: «Могҗизалар кыры». | 1 | 18.10.21. – 23.10.21. | |
| 9. | Кул эшләре күргәзмәсе. | 1 | 25.10.21. – 06.11.21. | |
| 10. | Халкыбызның күңел җәүһәрләре: «Татар халкының аш-сулары» *(чәй өстәле янында әңгәмә).* | 1 | 08.11.21. – 13.11.21. | |
| 11. | Мәктәп китапханәсенә сәяхәт. | 1 | 15.11.21. – 20.11.21. | |
| 12. | “Аулак өй” бәйрәменә әзерләнү. | 1 | 22.11.21. – 27.11.21 | |
| 13. | “Аулак өй” бәйрәмен үткәрү. | 1 | 29.11.21. – 04.12.21. | |
| 14. | Татар халык җырларын өйрәнү. | 1 | 06.12.21. – 11.12.21 | |
| 15. | Татар халкының милли киемнәре үзенчәлекләре. Хатын – кызлар һәм ирләр өчен бәйрәм һәм эш, концерт киемнәре. | 1 | 13.12.21. – 18.12.21. | |
| 16. | Хатын – кызларның бизәнү әйберләре. | 1 | 20.12.21. – 25.12.21. | |
| 17. | Алка һәм беләзек ясау. | 1 | 27.12.22. – 15.01.22. | |
| 18 | Татар җырчылары. Рафаэль Ильясов иҗаты белән таныштыру. | 1 | 17.01.22. – 22.01.22. | |
| 19. | Ризаэтдин бине Фәхретдин *(тәрбия дәресләре).* | 1 | 24.01.22. – 29.01.22 | |
| 20. | Ризаэтдин бине Фәхретдин *(тәрбия дәресләре).* | 1 | 31.01.22. – 05.02.22. | |
| 21. | Каз өмәсе үткәрү йоласы | 1 | 07.02.22. – 12.02.22. | |
| 22. | Кичке уеннар өйрәнү һәм уздыру. | 1 | 14.02.22. – 19.02.22. | |
| 23 | Язучы Фәнис Яруллинның иҗат юлы. | 1 | 21.02.22. – 26.02.22. | |
| 24 | Драматург Туфан Миңнуллинның иҗат юлы. | 1 | 28.02.22. – 05.03.22. | |
| 25 | Балалар язучысы Роберт Миңнуллин иҗаты белән танышу. | 1 | 07.03.22. – 12.03.22. | |
| 26. | Артист Равил Шәрәфиев иҗаты белән танышу. Спектакльләрдән өзекләр карау. | 1 | 14.03.22. – 19.03.22. | |
| 27. | Яшь җырчылар иҗаты белән танышу | 1 | 21.03.22. – 09.04.22. | |
| 28 | “Җырлыйк әле!” кичәсе үткәрү. | 1 | 11.04.22. – 16.04.22. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 29. | Киндерле елгасына экскурсия. Экологик мәсьәләләр турында сөйләшү. | 1 | 18.04.22. – 23.04.22. | |
| 30. | Үзеңнең нәсел – ыруыңны өйрәнү. | 1 | 25.04.22. – 30.04.22. | |
| 31. | Нәсел агачын ясау. | | 02.05.22. – 07.05.22. | |
| 32. | Татарстанның милли музеена экскурсия. | 1 | 09.05.22. – 14.05.22. | |
| 33. | Фотосессия “Нинди матур минем туган ягым!” | 1 | 16.05.22. – 21.05.22. | |
| 34. | Йомгаклау. Ел эшенә нәтиҗә ясау. | 1 | 23.05.22. – 31.05.22. | |

**Кулланылган әдәбият.**


1. Татар халык педагогикасы.
   Р.Х. Шәймәрданов, Ә.Т. Сибгатуллина, Р.Г. Сибгатуллин.
2. Әхлаклылык дәресләре.В.С. Казыйханов.
3. Татар халык әкиятләре.
4. “Алтын кашык” (такмаклар, сынамышлар, уеннар), Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1996.
5. “Балалар фольклоры”, Нәкый Исәнбәт, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1984.
6. “Тәрбия хәзинәләре”, С.Г. Исмәгыйлева, Ф.М. Исмәгыйлева, Яр Чаллы, 1995.
7. Г.Тукай әсәрләре.
8. Якташларыбыз иҗаты.